

Рузаевка районынын архив бvлеге - республикада ин яхшыларнын берсе. Менә инде 10 елдан артык аны талантлы кеше һәм акыллы житәкче Наилә Шаһидулла кызы Чугунова житәкли.
Рузаевка архивы тарихы 1936 елда башлана. Архивчыларнын ин топ бурычларыннан берсе - документларнын сакланышын тәэмин итv. Чонки әлеге учреждение - vткәннәр турындагы мәгълvматларнын уникаль саклагычы бит.
Монарчы Рузаевка архив бvлеге документларны саклау очен бернинди шартлар булмаган торак йортнын топ катында иде. Фондларны саклау һәм хезмәткәрләрнен эш шартларын яхшырту очен мәйданны кинәйтv мәсьәләсе кискен торды һәм моны чишvдә Шаһидулла кызы Наиләнен дә олеше зур. Шулай, 2016 елнын 26 октябрендә архив бvлегенен яна бинасы рәсми рәвештә ачыла.       Хәзер ул Ухтомский урамындагы 58 нче йортта ремонтланган бинада урнашкан; барлык заманча стандартларга һәм таләпләргә туры килә - махсус янмый торган киштәләр һәм шкафлар белән жиһазландырылган, анда ин моһим документлар саклана. Заманча янгын сигнализациясе һәм компьютер техникасы бар. Монда шулай ук даими (мәнгелек) сакланырга тиешле документлар булган бvлек бар. Бу, беренче чиратта, жирле vзидарә органнары, судлар һәм прокуратура документлары, жир килешvләре, торле бvләкләvләр, авыл жирлекләре турында тарихи белешмәләр.
Рузаевка архивында танылган як-ташларыбызнын, мактаулы граж-даннарнын шәхси фондларын да саклыйлар. Туу һәм vлем чиркәv язмалары, нотариаль гамәлләр язмалары, колхоз бvлекләре, безнен оешмаларнын барлык тарихи белешмәләре бар. Болар барысы да гражданнарга кирәкле мәгълvмат бирv, аларнын сорауларына жавап бирv очен кирәк. Әйтик, хезмәт хакы яки эш стажы турында белешмә. Районнын булачак пенсионерлары нәкъ менә шунда морәжәгать итәләр.
Наилә Шаһидулла кызы Чугунованын тырыш эшчәнлегенә ижади якын килvе һәм активлыгы очен район, рес-публика һәм Россия дәрәжәсендәге бvләкләнгән.
- Наилә Шаһидулловнаны мин кvптән беләм, 30 елдан артык. Мин ана зур хормәт белән карыйм. Белеме буенча ул тарихчы. Архив тармагында 33 ел, Рузаевка районынын архив бvлеге начальнигы булып 10 елдан артык эшли, - дип сойли РМ Мәдәният, милли сәясәт һәм архив эше министрлыгынын архив идарәсе башлыгы Людмила Чересева. - Наилә Чугунова - vз эшенен чын патриоты, намуслы, жаваплы, белемле һәм ижади кеше. Анын искиткеч оештыру сәләте бар. Документларнын сакланышын тәэмин итv очен кvп эш башкара, шулай ук архив урнашкан яна бина бvлеп бирvгә иреште. Яраткан эшенә бар кочен бирә.
Наилә Шаһидулла кызы житәк-челегендә тагын ике искиткеч белгеч эшли. Алар бергәләп югары дәрәжәдә зур кvләмдә эш башкаралар: кирәкле мәгълvматны жыю, саклау, аннары бирv буенча жентекле эш алып баралар.
Рузаевка архив бvлеге республика муниципаль архивлары арасында беренчеләрдән булып кvпфункцияле Үзәк белән хезмәттәшлек оештырган, ел саен социаль-хокукый характердагы запросларнын кvбесен vти, хәзерге вакытта Пенсия фонды белән

электрон элемтәдә эшли.
Наилә Шаһидулла кызы тормыш иптәше, Шамиль Әхмәтжан улы белән Мансур белән Артур улларын тәрбияләп vстерделәр, ә алар әти-әниләренә оныклар һәм оныкчыклар бvләк итте. Наилә Чугунованың гаиләсе бик тату; бергәләп татар милли ризык-ларын әзерләргә ярата, vзебезнен гореф-гадәтләрне саклый.

**Наилә НАСЫРОВА**